

СЕРГЕЙ ТИМОФЕЕВИЧ АКСАКОВ

# СЕРГЕЙ ТИМОФЕЕВИЧ АКСАКОВ

„Гимназия һәм университет тормышы, андагы иптәшләр — менә шулар минем өчен бөтен бер дөнья булды. Анда яшь мәсьәләләр хәл ителә, анда ялкынлы омтылышлар, тойгылар канәгатьләндерелә. Анда суд һәм хөкем итү, аклау һәм тантана бар иде... Күңлемдә сакланган яхшылыкларның һәммәсе өчен мин үземне гимназиягә, университетка бурычлы дип, андагы иҗтимагый таглиматка һәм аннан алып чыккан җанлы башлангычка бурычлы дип саныйм".

*С. Т. Аксаков.*

1.

Кичкә таба көн тагын да салкыная төште. Тирән карга күмелгән урамнар, юка бәс каплаган агачлар һәм йонлач толыпларга төренгән будочник фигуралары җиңелчә томан аша гына күренәләр иде.

Аяк астында кар шыгырдый. Өйләреннән тик мөһим эш өчен генә чыккан берән-сәрән җәяүлеләр тар тротуарлардан ашыгып атлыйлар иде. Көн тиз арада караңгылана барды. Елтырап торган бозлы — бизәкле тәрәзәләрнең кайберләрендә утлар күренде, тыкрыкларда төнге каравылчыларның шакылдавык тавышлары яңгырый башлады.

Гади генә чыпта кибиткага җигелгән, бәскә каткан тройка, шөлдерле муенсалар белән салмак кына чыңлап, Грузинский урамындагы биек чиркәүдән ерак түгел кечерәк бер йортның капка төбенә килеп туктады. Утыргычтан сикереп төшкән хезмәтче, озын толып итәкләренә урала-урала, эчкә кереп китте. Бер минуттан соң ул кибитка янына яңадан йөгереп чыкты һәм шатланып кычкырып җибәрде:

— Аллага шөкер, матушка Марья Николаевна! Капитанша Аристованың йорты шушы үзе икән. Мин инде килеп җитүдән өметемне өзә язган идем! Шәһәр буйлап ике сагәтләп адашып йөрү уен түгел бит...

Кибитка түреннән бик нык борчылган хатын-кыз тавышы ишетелде:

— Тизрәк, тизрәк... Ах, Сереженька өшемәгәе дип куркам!

Тройка ишек алдына керде. Шәмнәр тотып, крыльцога кешеләр йөгерешеп чыкты. Шатланып, күмәкләшеп дәшү, сорашулар китте. Юлчылар, оешкан аякларын язып, авыр толыпларын, дахаларын салдылар да, кагына-кагына өйгә юнәлделәр. Барыннан алда, мех юрганга төрелгән баланы күтәреп, хезмәтче барды.

Иркен бүлмәдә, ишле шәмле якты люстра турысындагы өстәлдә, самовар кайнап утыра иде. Тиз генә чәй эчеп, һәммәсе үзләренең урыннарына юнәлделәр, бүлмә караңгылыкка талды. Кечкенә Сережа бик нык өшегән һәм арыган иде, ул хәтта чәй эчкәч тә елына алмады, бары, урнына ятып, әнисенең елы куйнына сырышкач кына елынып, йоклап китте.

Мария Николаевна Аксакова таңга хәтле диярлек йокламыйча, улының тигез сулышын тыңлап ятты. Аның башында борчулы уйлар кайнады. Өзелеп сөйгән улының тормышы һәм сәламәтлеге өчен ул сигез ел инде менә шулай көн-төн куркып килде. Сережа туганда ук зәгыйф, ауру һәм нервлы бала булып туган иде, соңыннан да озак һәм каты авырды, терелтүдән өмет өзеп, хәтта докторлар да дәваламас булдылар.

Иң яхшы врачларга да мөмкин булып тоелмаган эшне ананың чиксез, кайнар мәхәббәте башкарып чыкты. Мария Николаевна ауру улының ятагы янында көннәр, төннәр буе китми утырды, аның салкыная барган тәнен үз сулышы белән елытты, бөтен көче белән аны үлемнән саклады, аның белән озак һәм армый-талмый көрәшеп килде, һәм ананың шул бөек мәхәббәте могҗизә ясады: Сережа терелде! Ә менә бу төнне барлык шушы мәшәкат һәм борчыларга тагын бер яңа хафа өстәлде: иркә өйрәтелгән, сигез яшьлек йомшак баланың бер үзен шушы

зур шәһәрдә, туган имение — Аксаководан дүрт йөз чакрым ераклыкта, ят кешеләр арасында калдырып китәргә кирәк иде. Ләкин бу котылгысыз иде, балага башкача белем бирү мөмкинлекләре юк иде.

Казанда Сережаны бик күп яңа нәрсәләр көткән икән. Икенче кичне Аксаковларның борынгы дусы Максим Дмитриевич Княжевич йортында ул үзенең Уфа иптәшләрен — Княжевичнең уллары — Дмитрий белән Александрны очрата. Аларны тиз генә танымый, малайлар биек, кызыл якалы, нindидер гаҗәп, яшел мундир кигән булалар; алар инде Казан гимназиясендә укыйлар, һәм тиздән аларны гимназиягә ат белән илтеп тә кайталар, чөнки алар өйгә сәгать кичке сигезгә хәтле генә җибәрелгәннәр икән.

Зурлар янында бер үзе калып, аларның сүзләренә колак салып утыра торгач, Сережа йокымсырап китә. Менә кинәт аның колагына куркыныч сүзләр ишетелә:

— Шулай, хөрмәтле Мария Николаевна, — ди Княжевич, — минем дусларча киңәшемне кабул күреп, Сережаны гимназиягә бирегез...

Ләкин Мария Николаевна көтмәгәндә аңа каршы төшә башлый. Княжевич никадәр генә тырышса да, аны күндерә алмый. Мария Николаевна кискен итеп ахыр сүзен әйтә: — Сережаны да, үземне дә аерылышып торырга хәзерләү өчен иң кимендә бер ел вакыт кирәк, бер елдан соң мин аны гимназиягә үзем китерәчәкмен, ди.

Берничә көннән соң, тук, авыл атлары җигелгән кибитка Казаннан кире чыгып китә: башта Сембер губернасына юнәләләр, анда Сережаның кечкенә апасы белән абыйсы калган була, ә аннан соң, Волга аръягына — Новое Аксаковога кайтып китәләр.

2.

Менә 1800 ел килә. Сизелмәстән, яз да үтеп китә, яшел чирәмле Бугуруслан буйларында гамсез шаярып йөрүләр белән җәй дә үтә, агачларны алтынга манган көз дә артта кала. Тугыз яшьлек Сережага укырга китәргә кирәк була. Ул моңардан курка. Ләкин улын һич шиксез гимназиягә бирергә карар кылган Мария Николаевна аны төрлечә юата,

белемле кешенең яхшы киләчәге белән кызыктыра. Ниһаять ул аны укуның кирәклелегенә ышандыра. Декабрьдә, беренче чана юлы төшкәч тә, Сережа үзенең әти-әниләре белән берлектә яңадан Казанга юнәлә.

Бу юлы эш озакка сузылмый. Гимназиядә буш урын була, язулар һәммәсе алдан хәзерләнгән була, һәм 1801 елның 15 январендә Тимофей Степанович Аксаков Сережаны гимназиянең вице-директоры Г. П. Герберга алып бара.

Вице-директор, юка гына коры иреннәрен кыймылдатып, Аксаковларның ясалма рәвештә матурлап язган прошениесен озак һәм игтибар белән укый. Прошение аңа ошый. Ул, нинди генә метекче булмасын, биредә устав формасына туры килмәгән кечкенә генә җитешсезлек тә тапмый. Укып чыккач, ягымлы гына елмаеп, Сережаны, белемен сынау өчен, класс инспекторы Левицкийгә алып керергә кирәклекне әйтә.

Левицкий авырган була, һәм Тимофей Степанович Сережаны аның квартирына алып китә.

Аксаковларны шат йөзле, кызыл чырайлы, юан гына бер кеше ягымлылык белән каршы ала. Бу рус әдәбиятыннан өлкән укытучы — класс инспекторы Лев Семенович Левицкий була.

Сынау озакка сузылмый. Сережа Карамзиннан бер өзек һәм Дмитриев шигырьләрен укып күрсәтә; аның укуына һәм язуының ачыклыгына сокланып, инспектор кечкенә Аксаковның „белемен“ мактарга керешеп китә. Өстәлгә барып утыра да бер кисәк күк кагәзгә язып та бирә:

Титулярный советник господин Аксаковның улы Сергейның белемен тикшердем: ул русча бик яхшы укый һәм яза.

Инспектор хезмәтен үтәүче укытучы
*Лев Левицкий.*

1801 ел
Январь 15.

Ниһаять бөтен эш тәмам була. Гимназия Советы Сергей Аксаковны казна хисабына тәрбияләнүче итеп кабул итәргә карар бирә. Сережаны „күркәм холыклылар“ яши торган бүлмә надзирателе Василий Петрович Упадышевский белән таныштыралар,

гимназия формасына киендерәләр, каты — сукно галстук тагалар, йомшак һәм алтын төсле чәч бөдраләрен кыркалар да Владимир Гофф дигән укучы белән янәшә куялар.

Әнисе белән аерылышу көннәре — авыр көннәр килеп җитә. Соңгы кичне бөтен төн буе диярлек ана белән бала сөйләшеп, яшь түгеп үткәрәләр. Иртә таң белән алар саубуллашалар: Мария Николаевнаның повозкасы заставага таба борыла, ә Сережа белән Евсеич, шулай ук атка утырып, гимназиягә юнәләләр.

Менә хәзер, зур, ак бинага якынлашкач кына, Аксаков үзенең гимназия укучысы икәнлегенә төшенә. Чал швейцар юан колонналар арасындагы биек крыльцо ишекләрен ачып җибәрә, һәм Сережа иркен, якты вестибюльгә барып керә, ә аннан икенче, өченче этажларга киң баскычлар менеп киткән була. Түбәнге этажда — укучыларның торак бүлмәләре, эконом һәм дежурный офицер квартиры, кладовойлар һәм контора урнашкан була. Икенче этажны — җыелышлар залы, столовой залы, класс бүлмәләре, инспектор квартиры һәм „азиатская типография“ били. Антресольдә[1] исә укытучылар, канцелярия хезмәткәрләренең квартиралары һәм больница урнашкан була. Ул вакыттагы Казан гимназиясе укучыларыннан берәүнең менә мондый сүзләрен китереп үтик:

> „Ашыкмыйлар иде ул заманда
> Зиннәтле зур йортлар салырга.
> Пастырь һәм дә пасомый
> Бергә ята иде йокларга“.

Провинциаль рус гимназияләре арасында Казан гимназиясе иң борынгылардан санала иде. Аның ачылуы 1755 елны Москва университетын оештыруга бик нык бәйләнгән. Яңа ачылган Москва университеты каршында — берсе дворян балалары өчен, икенчесе разночинец балалары өчен — ике гимназия оештырыла. Москва университетының директоры И. И. Мелиссино, Москвадан бик еракта торган, киң көнчыгыш краеның үзәге — Казанда, Москвадагы шикелле үк ике гимназия ачарга кирәк дигән мәсьәлә күтәрә.

---

[1] Антресоль — югарыдагы ярым этаж, тәбәнәк этаж.

Бу проектны университетның „кураторы“ (попечителе) Шувалов та яклый, һәм проект 1758 елның 21 июлендә Сенат тарафыннан кабул ителә. Сенат „фәнне үрчетү өчен“ Казанда „Москва университетындагы шикелле һәм шундый ук шартлар белән“ ике гимназия ачарга карар кыла. Яңа гимназияләрнең барлык расходларын Москва университеты күтәрә.

1759 елның башында Казанга Москва университетының асессоры, ул заманның шактый атаклы язучысы М. И. Веревкин килә. Ул гимназияләрнең директоры итеп, яки, шул вакыттагыча әйтсәк — „командиры“ итеп билгеләнә. 1759 елның 21 январендә Казан гимназияләре ачыла. Иң беренче 14 укучы арасында „Фелица“ның авторы булачак кеше — Г. Р. Державин да була.

Баштарак гимназияләрнең хәле шактый кызганыч була. Аена 15 сум бәрабәренә ике этажлы, яртылаш җимерек бер йорт табалар, укытучылар составы да белем ягыннан шулай ук бик шикле була. Поручик Морозов геометрия һәм фортификация укыта, студент Моревка „дөрес язу кагидәләре һәм латын теленең беренче башлангычы һәм штиле“ тапшырыла. Дәреслекләр, укыту ярдәмлекләре булмый.

30 ел чамасы яшәгәннән соң, 1785 елны гимназия Җәмагәт Тәрбия йорты приказы карамагына бирелә, тиз арада начарлана башлый, Москва университеты белән барлык бәйләнешләрне өзә һәм 1788 елда бөтен бер 10 елга ябылып та куела. 1798 елның 29 маенда Павел I Казанга килгән вактында гимназиянең уставына кул куя, Воскресенский урамда эшләнеп бетеп килә торган губернатор йортын аңа бирә, һәм Казан гимназиясе яңадан яши башлый. Сережа Аксаковны 1801 елда инде менә шул гимназиягә укырга бирәләр.

Гимназиядә Сережага һәммә нәрсә аңлаешсыз һәм куркыныч тоела. Бүлмә надзирательләре укучыларны иртән бик иртә, караңгы белән үк, уяталар. Юынудан, стройга тезелеп чиксез күп йөрү белән көн башлана: гыйбадәткә, иртәнге ашка, дәрескә... һәммәсенә строй белән баралар. Ашау такыр һәм начар була.

Гимназия тормышының ялыктыргыч бер төрле, авыр көннәре, атналары сузыла. Сережа бик нык

ямансылый. Аның нерв еянәкләре яңара. Ул каты аурый.

Ахрында, Аксаковның дядькасы — Евсеич — аның авыруы турында Мария Николаевнага хәбәр итәргә карар бирә.

Язгы юл өзеге була. Юллар эрегән, һичбер йөрерлек булмый. Ләкин, шуңа карамастан, Мария Николаевна, хатны алу белән үк, Казанга чыгып китә. Ул көн-төн туктаусыз бара, батып үлү куркынычына карамастан, Кама аркылы чыга һәм 12 көн дигәндә — апрель урталарында — Казанга килеп җитә һәм авыру улын күрә.

Аның бердәнбер теләге — Сережаны гимназиядән тизрәк алып китү була. Ләкин бу эш бик мәшакатьле булып чыга: директор һәм докторлар белән сөйләшү — аңлашу айдан артыкка тартыла.

Ана белән бала, түземсезлек белән гимназия Советы карарын көтәләр, эш уңышлы хәл ителә: врачларның нык тырышуы өскә чыга.

Гимназиядәге азаккы көн сизелмичә үк үтә. Сережа инде туйдырып бетергән гимназия мундирын салып ташлый, үзенең өйрәнгән элекке киемнәрен киеп ала, болар шунда ук әллә нихәтле шатлык һәм күңелле хатирәләр бирә. Тик В. П. Упадышевский белән саубуллашу гына шатлыкны беркадәр киметә, чөнки Сережа аны бик яраткан була.

Өченче көнне инде таң белән, әле йокыдан уянмаган Казан мостовойларын дөбердәтеп, Аксаковларның каретасы яшел кырлар, болыннар киңлегенә чыга...

3.

Бер елга якын вакыт Сережа үзләренең Аксаково имениесендә үткәрә[1]. Гүзәл табигать; яраткан эш белән — үз-үзен оныту дәрәҗәсенә җитеп балык тоту эше белән шөгыльләнү, китап уку, прогулкалар, аны әйләндереп алган кешеләрнең мәхәббәте һәм кайгыртучанлыгы — аны тәмам терелтә. Ул тиз арада ныгый, элеккечә шат күңелле, дәртле малайга әйләнә. 1802 елның мартында Сережаны тагын Казанга озаталар.

[1] С. Т. Аксаковның „Воспоминания" дигән автобиографик әсәре бар; ул анда Казан гимназнясендәге, ә аннан соң университеттагы тормышын яза (китап 1856 елда басылган). 50 ел элек булган барлык вакыйгаләрне С. Т. Аксаков гәрчә гаҗәп бер төгәллек белән тасвыйрласа да, „Бер ел авылда" һәм „Гим-

Бу юлы Аксаковлар капитанша Аристова йортына төшмиләр, ә үзләренә кечерәк бер аерым йорт алалар. Шунда ук алар янына Василий Петрович Упадышевский килеп җитә һәм гимназиядә булган үзгәрешләрнең барсын сөйли. Москва университетының яшь адъюнктларыннан Иван Игнатьевич Запольский һәм Григорий Иванович Карташевский карамагында укучылар үз кесәләреннән ашап яши торган пансион була. Упадышевский Сережаны менә шул пансионга кертергә киңәш бирә. Әлеге Запольский белән Карташевский шул ук вакытта Казан гимназиясендә укытучы булып эшлиләр: беренчесе физика, икенчесе математика укыта.

Икенче көнне Мария Николаевна үзенең Сережасын И. И. Запольский тәрбиясенә илтеп тапшыра.

Әнисе белән икенче тапкыр аерылышу яшь Аксаков өчен инде шактый җиңел була. Яңа шартларда яши башлау аркасында соңгы сагышлар да тәмам тарала. Гимназия инде Сережага элекке шикелле авыр тәэсир итми, иптәшләре дә бер дә начар түгел, ә шат күңелле, простой егетләр булып чыга.

1803 елны гимназия өч класска бүленә, унике яшьлек Аксаков та икенче класска күчә. Бирелә ул бер кеше белән, әле генә Москва университетыннан Казанга күчерелгән укытучы, рус теле һәм рус әдәбияты укытучысы Николай Михайлович Ибрагимов белән очраша һәм соңыннан аны гомер буе сөеп искә төшерә. Ибрагимов үз эшен нык белүче, яхшы укытучы була. Диктантлар өчен Карамзин, Дмитров, Ломоносов, Херасков әсәрләренең иң яхшы урыннарын сайлый, бу язучыларның иң яхшы әсәрләрен укырга һәм аңлатып бирергә мәҗбүр итә, шулай ук укучыларның үзләреннән кечерәк пьесалар яздырып карый. Аксаковның әдәби юнәлеш алуына Ибрагимов зур йогынты ясый, әдәбиятны чын-чынлап төшенергә, аны яратырга мәҗбүр итә.

1804 нче елның башында, ул елны Казанда бик

---

назия" дигән бүлекләрендә (икенче чор) бер хата җибәрә. Аксаков: Казаннан 1801 елның маенда китеп, гимназиягә яңадан икенче елның август аенда гына килдем дип яза. Дөресе — авылда ул 14 ай түгел, ә бары 10 яки 9 айлап кына тора. 1802 елны укучыларның өлгерешләре язылган исемлектә апрель, май, июнь айларында Сергей Тимофеевичнең дә исме бар.

нык таралган бизгәк авыруыннан терелгәннән соң, Аксаков Григорий Иванович Карташевский карамагына күчә. Ул моңа сөенеп бетә алмый. Карташевский болай карауга коры һәм каты табигатле, ләкин гадел һәм чын күңелле кеше була, Аксаков аны бөтен җаны белән ярата.

Карташевский җидди рәвештә Сережаны тәрбия итәргә керешә. Аның әдәбиятка булган мәхәббәтен белеп, бик күп китап сатып алып бирә, болар арасында Ломоносов, Державин, Дмитриев, Капнист, Хемницер, Сумароков, Херасков әсәрләре дә була. Француз китаплары да онытылмый, болардан — Масильон, Флешье, Бурдалу әсәрләре, Шехерезада әкиятләренең, „Дон — Кихот"ның, „Авель үлеме"нең, „Вакфильдский священник" һәм башкаларның французча тәрҗемәләре сайлана. Өч айдан соң инде Аксаков француз телендәге китапларны җиңел укырлык булып җитә.

Рус әдәбиятын ул аеруча яратып укый. Державинның, Ломоносовның иң яхшы әсәрләрен күрми белә. Ләкин Г. И. Карташевский хәзергә әле аны бер нәрсәдән — язу эшеннән — тыеп килә. Сережа, бер дә искәрмәстән, моның сәбәбенә дә төшенә.

Аксаковның бүлмәсе Карташевскийнең кабинетыннан юка такта белән генә бүленгән була. Бер көнне китап укып утырганда, Сережа үзенең тәрбиячесе Карташевский белән Н. М. Ибрагимовның кычкырып сөйләшкәннәрен ишетә. Сүз моның турында бара: Ибрагимов Сережаның класста „Яз матурлыклары" темасына язылган сочинениесен мактый, Сережага мондый сочинениеләр белән күбрәк шөгыльләнергә кирәк иде ди. Ә Григорий Иванович, ризасызлык күрсәтеп, аның сүзен бүлә:

— Юк сүз ул, дустым, — ди. — Аның сочинениесе төрле китаплардан чүпләп алган хәзер фразалардан гына тора, шуңа күрә үз таланты бармы, юкмы икәнен белү кыен. Аның теләге зур, тиздән кагәз пычрата башлаячагын белеп үк торам, ләкин мин аны мөмкин кадәр озаграк тыеп торачакмын: язарга никадәр соңрак башласа, шул кадәр үк әйбәтрәк булачак. Иң кирәге — шома һәм дөрес язучыларны укып, яхшы үрнәкләр, образлар алсын, үз вкусларын булдырсын.

Менә 1804 елның язы килә. Июньдә экзаменнар тәмам була, авылдан килгән тройка Сережаны һәм аның тәрбиячесен Аксаково имениесенә алып кайтып китә.

Тимофей Степанович үзенең күптәнге вәгдәсендә тора: улына мылтык алып бирә. Сережа бик дәртле аучы булып китә, бөтен вактын сазлыкларда, болыннарда, урманда йөреп үткәрә. Аучылык дәрте тиз генә сүрелми, элеккечә китап уку эшенә, үзенең яраткан апасы белән прогулкаларга чыгарга, балык тотарга йөрергә тик шактый вакыттан соң гына керешә ала.

Карташевский һәм Сережа Казанга 15 августта кайталар, аларны анда күңелсез яңалыклар көтеп торган була. Ләкин Карташевский аларны үзенең шәкертеннән яшерә,ниләр булганлыгын Сережа бары ике атнадан соң гына белә.

Гимназиянең директоры Лихачев бик сай акыллы һәм куркак кеше була. Аны укучылар да, укытучылар да яратмыйлар. Бер көнне, (бу әле җәйге каникулга хәтле була) обед вактында, ашханәдә тавыш күтәрелә: кемнеңдер боткасыннан шәм кисәге килеп чыга.

Шул төнне, ниндидер бер куркусыз кеше, гимназиянең стенасына, югарыга, түшәм кырна ук, директорны әшәке сүзләр белән мыскыллап, эре итеп, кызыл карандаш белән язу язып куя. Гаепле кеше табылмый. Шуннан соң озак та үтмәстән, тагын да яманрак хәл чыга.

4 июньдә, гимназия ишек алдында гулять итеп йөргәндә, укучылар сүгенү тавышлары ишетәләр. Карасалар, квартирмейстер Михайловның гимназия хезмәткәрләреннән берсен таяк белән кыйнап торуын күрәләр. Укучылар бу җәзалауны тиз туктатуны таләп итәләр. Телләшү китә, Михайлов тарафыннан мыскылланган Александр Княжевичны яклап, аның абыйсы Дмитрий тавыш күтәрә. Михайлов үзенең квартирына кереп качарга мәҗбүр була, укучыларга:

— Сезнең арада бер генә юнле кеше дә юк, сез барыгыз да юлбасарлар! — дип кычкыра.

Надзиратель Попов, чикләреннән чыккан укучыларны көч-хәл белән генә тынычландырып, вакыйгане баш надзирательгә — карт Фишергә, ә Фишер — Лихачевка җиткерә.

Укучылар Михайловка җәза бирүне таләп итәләр, ләкин Лихачев тыңламый. Шуннан соң бик каты тавыш, шау-шу күтәрелә, нәтиҗәдә Лихачев куркып кача.

7 июньдә 30 укучы бергә җыелып, контора ишек төбенә килә, алар Михайловны эштән алуны тагын таләп итмәкче булалар. Директор аларны кабул итми. Дмитрий Княжевич шул чаклы дулкынлана, ул хәтта елап җибәрә һәм:

— Тикшерми икән, директорның үзен кыйныйбыз! — дип кычкыра.

Конфликт аның саен тирәнәя. „1804 елның 4, 6 һәм 8 июнендә укучылар арасында булган тәртипсезлекләр турында... 94 битлек дело“да без инде мондый сүзләрне укыйбыз: обед вактында „кемгәдер икмәк ыргытканы өчен, надзиратель Лапшин өлкән Евреиновны ашханәдән чыгарып җибәргәч, дворян малайлары өстәлендә тавыш күтәрелә“. Кичен карт Фишер тагын да ныграк гаҗәпкә кала: укучылардан Пафомов, Княжевич, Перевощиков һәм башкалар, Балясников дигән укучыдан кларнет уйнаттырып, марш атлап, Лапшин бүлмәсенә барып керәләр, „аңа әдәпсез сүзләр әйтәләр, киемнәренә генә түгел, хәтта күзләренә, башына да ботка чәпиләр“.

Михайлов та, Фишер дә, хәтта Лихачев үзе дә бик нык шүрлиләр. Михайлов директорга рапорт та язып бирә: квартирымнан чыгарга куркам, чөнки укучылар „явызланып, сәламәтлегем өчен дә, тормышым өчен дә бер-бер зарарлы нәрсә эшләмәгәйләре“ ди.

Август урталарына хәтле эш әнә шулай бара. Укучылар әкренләп сүреләләр, ләкин шул арада гимназия Советының үзендә чуалчыклык башлана. Ахырда эшкә Казан учебный округының попечителе Румовский катнаша. „Казна тәрбиясендә яшәүче“ тугыз укучыга җәза бирелә: Княжевич, Пафомов, Крылов һәм Алехинны гимназиядән чыгаралар, Балясниковны, Кузьминскийны һәм ике Петровны „атна буена каты арестка дучар итәләр“, Упадышевскийны 3 көнгә карцерга ябалар.

Педагоглар белән тагын да катырак эш кылалар. Фишер, „үз хезмәтенә сәләтсез, яисә картлык сәбәпле җигәрсез“ табылып, отставка ала; „яшьләрнең

ертлачлануына юл куйганлыктан, явызлыкны сизгәч үк туктату чарасына ныклап керешмәгәнлектән", Лихачевны да эштән алалар. Гимназиянең баш надзирателе һәм директоры итеп Яковкин билгеләнә.

Аксаков гимназиягә баргач, иптәшләре аңа менә шуларның барын сөйләп бирәләр.

Тыныч кына укып барган чакта, кыш урталарында, яшь Аксаковнын тормышында күтелмәгән бер вакыйга була; мылтык алып ауга йөри башлау аңа нинди тәэсир ясаган булса, бу да шундый ук тәэсир ясый. Аксаковның абзыйсы А. Н. Зубов аны ике тапкыр Казан театрына алып бара.

Бу беренче спектакльләр яшь Аксаковның хыялын шундый нык кузгаталар, — ул, укуны ташлап, бары театр белән генә саташа башлый. Григорий Иванович Карташевский аны көч-хәл белән генә акылга китерә ала. Театр белән кызыксыну беркадәр сүрелеп, уку эшләре элекке эзенә төшкәннән соң, Карташевский театр турында аның белән үзе сөйләшә башлый, театр тарихы, атаклы артистлар тормышы белән аны ныклап һәм төпле рәвештә таныштыра.

Менә бер көнне, Аксаков әле генә гимназиядән кайтып, кичке чәен эчеп утырганда, бүлмәгә Карташевский килеп керә дә, шат күңел белән: „без хәзер бер җиргә барырга тиешбез" дип аңлата. Аксаков тиз генә киенә, чыгып, Григорий Иванович янына чанага утыра, кая барганны белергә тырышып, баш вата.

Кучер атны театр бинасына таба боргач, Сереженың йөрәге жу итеп китә, үз күзләренә үзе ышанмый. Театрның нык яктыртылган ишек төпләренә зур афишалар элеңгән, анда: бүген театрда „Колбасники" дигән опера куела, артистлардан Михаил Калмыков, Прытков һәм Аникеевлар катнаша дип язылган була.

Озакламый Аксаков „Недоросль", „Ошибки или утро вечера мудренее" пьесаларын, „Нина или сумасшедшая от любви" операсын, Коцебунын „Граф Вальтрон" исемле драмасын карый. Театрга булган мәхәббәт көннән-көн арта, Аксаков бары әнә шул театр карау хозурлыгыннан мәхрум калмас өчен генә тырышып укырга мәҗбүр була. Шулай да тәрбия-

чесеннән яшереп, барлык рольләрне күрми белү дәрәҗәсендә өйрәнә, уйнап чыга. Моның өчен я бүлмәгә бикләнеп утырырга, я буш антресольгә кереп качарга кирәк була!

1804 елның кышында Аксаков үзенең классдашы Александр Панаев белән бик нык дуслаша. Аларның һәр икесен театр һәм әдәбият сөю якынлаштыра.

Ул вакытларда Александр Панаев „Аркадские пастушки" дигән айлык кулъязма журнал чыгара торган була. Анда: Адонис, Дафнис, Ирис, Палемон шикелле идиллик имзалар белән, буяулы, татлы телле хикәяләр, шигырьләр язылып килә.

Бик үк мактарлык булмаган һәр төрле одалар, Карамзинга ияреп язган әйберләр арасында журналның март номерында без Нереиснның (Николай Панаевның) кызыклы бер мәкаләсен күрәбез, анда ул „Казанская Швейцария" дигән исемнең каян килеп чыкканлыгын аңлата. Шул мәкаләдән бер өзек китереп үтик.

„Үткән җәйнең азакларында, гадәттәгедән шактый иртә торып, Казанның читенә чыгып йөрмәк булдым; үзем белән сөекле Карамзинны да алган идем, уйланып китеп, бөтенләй дә таныш түгел урынга барып чыкканмын; карыйм һәм... бу гүзәл урынга хайран калам... аннары, арыганлыктан, яшел чирәмгә барып утырам, — кесәмнән рус сәяхәтчесенең Хатларын алып, ачам да, укый башлыйм... аның белән бергә Швейцария шәһәрләрендә гизәм... Әй син, шашкын хыял! Төньяк кешесен син артык еракка, бәхетле Гельвеция илләренә алып киттең! Ах! Мин Казанда бит... Татлы хыял, син хәзер югаласың, бөек табигатнең әле генә күңелемне рәхәт тойгылар белән тутырып торган тиңдәшсез, матур ландшафтларын да үзең белән алып китәсең!..

Шунда мин укудан туктыйм, Швейцария күренешләрен шушы урыннар белән чагыштырам һәм... беркадәр ошашлык та табам шикелле; шул төпсез чокырларны, шул шайтан күперен, җиңүләре белән мәңге онтылмас Россия Геркулесын, ватан өчен җан-тән янучы, аны сөюче Геркулес гаскәренең шул күпер аша чыгуын күрәм шикелле.

... Шуннан соң, урнымнан торып, башка җирләрне карап чыгам, үземне батыр патриот Вильгельм Тель

ватанында итеп тойгандай булам. Һәр төрле күренешләргә аның саен сокланып, озак йөрим... менә ахырда дөньяның бөек патшасы үзенең ярты көнлек юлын йөреп чыга... Көн эсселәнә! Һәм мин өйгә обедга кайтырга карар бирәм.

... Миңа зур хозурлыклар биргән шушы прогулка турында иптәшләремә сөйлим; бу урыннарны минем белән бергә алар да мактыйлар, һәм без бергәләп аларга „Казанская Швейцария“ дигән исем бирәбез“.

4.

1804 елның көзендә Казан гимназиясен, бигрәк тә аның югары классларын, күтәренке һәм шатлыклы дулкынлану настроениеләре чолгап ала. Казанда университет ачылу турында бер елга якын сөйләнеп киленгән хәбәр тулысы белән дөресләнә. Казанга рәсми хәбәр килеп төшә, — 5 ноябрьдә университет уставы тасдыйк ителде һәм аңа попечитель итеп действительный статский советник С. Я. Румовский билгеләнде диелә. 1805 елның 11 февралендә Румовский үзе дә Казанга килә, ә өч көннән соң — 14 февральдә — университетны ачу уңае белән гади генә тантана үткәрелә.

Гимназия залына директор Яковкин һәм өлкән укытучылар җыела. Озак көткәннән соң, ишекләр ачылып китә, залга Румовский керә. Кулында зур күн папка, аннан ефәк шнурга беркетелгән бик зур сургуч печать асылынып тора, ул, папканы ача да, беразрак калтыравык тавыш белән, университетны тасдыйк итү грамотасын укырга керешә:

„Мәрхәмәтле Анабыз Гасударыня Императрица Елизавета Петровна, башка күп гүзәл эшләр белән берлектә, 1758 елны Казанда Гимназия ачып, зур илтифат күрсәткән һәм шуннан элек кенә Москва Университетына биргән кайбер хокукларны аңа да бүләк иткән иде. Россияне яңа баштан үзгәртеп коручы бөек Анабызның якты хатирәсе хөрмәтенә һәм Аның үрнәге буенча, заманыбызның гыйлем дәрәҗәсенә дә туры китереп, шул ук урында Университет төзәргә, бу затлы йортның яшәвен мәңгеләштерергә, ватаныбызга файдалы гражданнар хәзерләүдә,

гыйлем тарату бурычларына ирешүдә аңа мөмкинлекләр бирергә булдык вә һәм дә Үзебез һәм киләчәк балаларыбыз өчен түбәндәгечә карар кылабыз...“

Шушында җиткәч, Румовский тирән сулап куя һәм инде тантаналы тонны бераз киметә төшеп, грамотаның 21 нче статьясен укый, анда исә Университетның хокуклары, „төп нигезләре“ язылган була.

Шуннан соң Румовский моңарчы гимназия директоры булып эшләгән Яковкинның тарих, география һәм статистика профессоры итеп билгеләнүе турында укый, чөнки ул „үзенең басма әсәрләрендә бу предметлар буенча эш күрсәткән“ була. Гимназиянең дүрт укытучысы — Карташевский, Запольский, Левицкий һәм Эрих — адъюнкт булып билгеләнәләр.

Шулай итеп Казан Университеты яши башлый. Румовский председательлегендә атна буена Совет конференциясе бара, — гимназиянең югары классларындагы иң яхшы укучылар студентлыкка күчереләләр, кирәкле справкалар җыялар, укучыларның әтиләренә, ризалык сорап, хатлар җибәрәләр. 1804 елгы устав буенча университет 4 бүлектән (факультеттан) торырга тиеш була: „эхлакый һәм политик фәннәр факультеты, физика һәм математика фәннәре факультеты, врачлык яки медицина фәннәре факультеты һәм көнчыгыш телләре кафедрасы белән берлектә әдәбият факультеты; барлыгы 28 профессор, 12 адъюнкт, 6 лектор һәм укытучы эшләргә тиеш була. Беренче устав университетка сайлаулы ректор һәм деканнардан торган самоуправление булдыруны күз алдында тота, болар шул ук вакытта Совет составына керергә тиеш булалар. Ләкин бу кагәздә генә кала! Казан университеты үз гомрен гимназия директоры Яковкинның ялгыз идарә итү нигезендә башлап алып китә; ректор да, профессорлар да, студентлар да, бина да булмый. Менә гимназия бинасының бер өлеше университетка бирелә, кайбер укытучылар профессор яки адъюнкт булып китәләр, ә укучылар студент итеп „билгеләнәләр“.

1805 елның 22 февралендә гимназия укучыларын залга җыялар һәм попечитель алдында И. Ф. Яковкин аларга уставны — укучыларның бурычлары ту-

рындагы статьяләрне укып күрсәтә, Казан Университеты студентларының составын аңлата. Исемлектә беренче булып ундүрт яшьлек Сергей Аксаков язылган була. Исемлеккә барлыгы 33 укучы кертелә. Яковкинның студентларны „киләчәктә ватанга белем һәм саф күңел бүләк итәргә“ чакрып сөйләгән речьннән соң, Румовский студентларга шпага тапшыру буенча тантаналы церемониягә керешә, бу исә элекке вакыттагы рыцарьлек җоласына ошап китә. „Студентлыкка күчерелүчеләрнең“ кайберләре ахырда үз талантларын күрсәтәләр: Кондырев белән А. Панаев — Румовскийне тәбрикләп шигырь укыйлар, Панов аңа „сөяктән әйбер эшләү буенча үз һөнәренең кайбер тәҗрибәләрен“ тәкдим итә.

1805 нче елның август ахырларында университет аудиторияләрендә беренче лекцияләр башлана. Укыту эшләре бик тә тәртипсез формада алып барыла: факультетларга бүленү һичбер булмый. Һәрбер студент барлык лекцияләрне: математика һәм анатомияне, статистика һәм физиканы, тарих һәм ботаниканы, латин һәм грек әдәбиятын, географияне... тыңларга тиеш була. Университетта укытыла торган фәннәргә бик җиңел караш хөкем сөрә, шуңа күрә күп кенә студентлар, шул исәптән Аксаков та, университет лекцияләрен тыңлау белән берлектә гимназиядә укуда дәвам итәләр.

Аксаков һәм аның иптәшләре — Панаевлар, Перевощиков һәм башкалар, көндәлек дәресләрдән тыш әдәбият белән күп шөгыльләнәләр, Мармонтель повестьләрен тәрҗемә итәләр, бер-беренә үзләренең хикәя һәм шигырьләрен укыйлар. Бөтен бер „әдәби җәмгыять“ оеша, шунда ук кульязма журнал булдыру фикере дә туа, һәм ул „Безнең белемнәр журналы“ исме белән чыга да башлый. Гимназиядәге „Аркадские пастушки“ белән чагыштырганда бу инде шактый җидди, яхшы ук җитлеккән әдәби тәҗрибә була. 1806 елны „Рус әдәбияты сөючеләр“ түгәрәге төзелә, ул да тиздән рәсми җәмгыятькә әйләнә, анда исә Н. М. Ибрагимов, студентлардан В. һәм Д. Перевощиковлар, А. һәм И. Панаевлар, П. Кондыров, „нижне-российский класс“ укытучысы Д. Г. Богданов һ. б. чыгышлар ясыйлар.

1806 елның 17 декабрендә „Рус әдәбияты сөюче-

ләр җәмгыятенә“ С. Т. Аксаковтан хат тапшырыла, ул анда үзен җәмгыят члены итеп алуны сорый. Хатка каршы менә мондый җавап бирелә: „господин Аксаков үзенең хатына бер төрле дә әдәби тәҗрибә үрнәкләре беркетмәгән, шуңа күрә аңа господин Секретарь аркылы белдерергә кирәк: әнә шул шартны үтәми торып, җәмгыят аңа уңай җавап бирә алмаячак“. Икенче утырышта И. Панаев — Сергей Тимофеевичның „Кыш“ исемле шигырен тапшыра һәм Аксановны җәмгыяткә член итеп алалар.

1805 — 1806 елларның кышында университет яшьләре театр белән бик нык мавыгалар. Кичке лекцияләрне бетерми китәргә туры килүгә карамастан, алар һәр көн театрга йөриләр. (Ул вакытларда театрда Москваның атаклы артисты Плавильщиков гастрольләре бара). Профессорлар һәм укытучылар студентларның бер өлешенең лекциягә килмәүләренә игтибар итмиләр, ә инде үзе дә театр сөюче булган Н. М. Ибрагимов, лекциясен тәмамламыйча ук, еш кына:

— Я, господа, театрга барырга вакыт түгелме? — дип сорый торган була.

Плавильщиковның уйнавы Аксаковны һәм аның иптәшләрен шундый кызыктыра, — алар, гимназиядәге шикелле үк, үз көчләрен сәхнәдә тагын сынап карарга булалар. Озак та үтмәстән, казна тәрбиясендәге студентларның торак бүлмәсендә Веревкинның „Так и должно“ (Шулай булырга тиеш) исемле комедиясе һәм Сумароковның „Приданое обманом“ (Алдашып придан алу) дигән пьесасы уйнала. Тамашачылар студентларның уеннарына хәйран калалар. Баш рольләрнең берсен башкарган Аксаков исә — сәхнәгә „университеттагы аксак сторожның ертык мундирын киеп чыга; башына — акбурлы сүс парик кигән, кулына ишек алдындагы бәй этенең чылбырын тоткан була: ә эт, шул кичне ирекә җибәрелә дә, кемнедер бик каты тешли“.

Тиздән „күркәм холыклы булу өчен“ студентлар университетта декорацияле, пәрдәле, кулислы театр кую хокукы алалар. Ныклы труппасымак бер коллектив та төзелә, аның директоры итеп Аксаковны сайлыйлар.

Ул вакытларда Университетта үзенең лекцияләре

белән зур уңыш казанган бердәнбер профессор итеп натураль (табигать) тарих профессоры К. Ф. Фуксны күрсәтергә мөмкин. Ул үзе атаклы врач, ориенталист, нумизмат[1], этнограф, археолог, публицист була һәм бу өлкәләрдә зур белгеч, фәнни тикшеренүләргә юл салучы булып санала.

Тиз мавыгучан, кызыксынучан һәм яшьтән үк табигать сөюче, дәртле Аксаков — Фуксның иң тырыш шәкертләреннән берсе була; Аксаковның студентлар тормышыннан алып язылган „Күбәләкләр җыю" исемле гүзәл хикәясе нак менә профессор Фукс йогынтысы нәтиҗәсе дип шикләнми әйтергә мөмкин. Аксаков үзенең иң якын дусты Александр Панаев белән бергә бөтен буш вактын бакчаларда, болыннарда, урманнарда күбәләк куып үткәрә.

Бәйрәм көннәрне алар, кояш чыкмас борын үк торып, шәһәрдән 6—7 чакрым читкә китәләр. Кызып янган битләргә иртәнге салкын җил исә. Иртәнге гүзәл табигать, матур урыннар, ау белән чиксез мавыгу — һәммәсен оныттыра...

Студент В. И. Панаев үзенең истәлекләрендә яза: „Көз якынлашып, августның тын һәм айлы төннәре башлангач, без кичке аштан соң университетның ишек алды яклап зур крыльцосына җыелырга ярата идек; баскычка тезелешеп утыра идек тә, Гроздовскийның кларнетына кушылып, нык бирелеп, тирән хис белән, рус көйләрен ерлый идек. Моңлы ер авазы киң ишек алларына тарала иде. Университет бинасында торучы Яковкин безне бу хозурлыктан тыю гына түгел, ә үзенең дә тәрәзәләрен ачып куя, бөтен семьясе белән тыңлый иде".

Вакыт сизелми үтә бирә һәм 1807 елны Аксаков, ата-аналарының көчләве буенча, „статский эшкә керешү өчен" дип, университеттан чыгаруны сорый. Бу чорга караган истәлекләрендә Аксаков болай яза: „Оят булса да әйтергә тиешмен; — яраткан предметларны искә алмаганда, минем укулар йомшак барды, мин бик күп башка нәрсәләр белән мавыктым". Сергей Тимофеевичның үзенең әнә шундый истәлекләренә караганда, аның Казан университетыннан алган

[1] Ориенталист — көнчыгыш халыкларының телләрен, йолаларын белүче белгеч; нумизмат — борынгы акчалар белгече.

белеме чынлап та тирән дә, тулы да булмый, ләкин гомеренең иң матур чагын Казанда үткәргән Аксаков — гимназияне, университетны, үзенең иптәшләрен иң соңгы көннәргәчә мәхәббәт һәм чын күңеллелек белән искә төшерә. „Мондый елларның хатирәсе, — ди ул, — кешенең үзенә дә сизелмәстән, аерылмый яши бирә, гомер буе аның юлын яктыртып, юнәлеш биреп тора, язмыш аны кая гына алып кермәсен, ул нинди генә былчырак һәм сазлыкка батмасын, — әнә шул хатирә аны саф һәм туры юлга алып чыга“.

Якын университет белән, шау-шулы яшьлек тормышы, яшьлекнең кире кайтмый торган чоры белән аерылышу авыр була. Иртәгә китәм дигән көнне Аксаков иптәшләре белән саубуллаша. „Кочаклашып, тезелешеп, барлык бүлмәләрне, аудиторияләрне, залларны йөреп чыктык. Аннан соң озак-озак үбештек, кочыштык. Студентлар, хәтта гимназистлар да, гомергә саубуллашып, мине озатырга крыльцога чыктылар; мин баскычтан әкрен генә төшеп киттем; бик күңелсез һәм авыр булды; артыма борылып, иптәшләремә, университет бинасына тагын бер тапкыр карап алдым да, — йөгерә-атлап китеп бардым... арттан: „хуш, Аксаков, саубул!“ дигән таныш тавышлар яңгырады“.

5.

Илле ел вакыт узып китә. Русның танылган язучысы Аксаковның картлык көннәре якынлаша. Аның „Балык тоту турында язмалар“, „Аучы язмалары“, „Аучы хикәяләре һәм аучы язмалары“ дигән әсәрләре басылып чыга. Н. В. Гоголь белән дуслашу — Аксаковның реалистик иҗат юнәлеше алуына көчле этәреш ясый. Гоголь сүзен тыңлап, Аксаков Багровлар семьясе эпопеясен язарга керешә: „Семья хроникасы“, „Воспоминания“ (Истәлекләр), „Детские годы Багрова — внука“ (Багров внугының балалык еллары) әсәрләре килеп чыга. Аксаков әсәрләренең гүзәл стиле һәм тел чисталыгына русның иң танылган язучылары да сокланып карыйлар, һәм аның әсәрләре бу көнгә хәтле үзләренең реаль художество кыйммәтләрен саклыйлар.

Еллар үтү белән бергә үткәннәрнең истәлеге дә сүнә бара, ләкин кинәт Сергей Тимофеевич яңадан

бик ачык һәм җанлы итеп Казанны, Университетны, кире кайтмас яшьлек көннәрен хәтерли: аңа Петербургдан көтелмәгән бер хат килә:

„Хөрмәтле әфәндем

Сергей Тимофеевич,

Хәзерге көндә Петербургда яшәүче элекке Казан Университеты шәкертләре, Университетның ачылган көне — 5 ноябрьдә, студентларның беренче чыгарылышына илле ел тулу уңае белән, бергәләшеп мәҗлес үткәрергә булдылар.

Бергә җыелган студентлар арасында сезнең белән бер курста укыган беренче чыгарылыш студентлар бар, алар сезне элекке иптәш итеп һаман хәтерлиләр һәм яраталар; шулай ук соңгырак чыгарылыш студентлар да, гәрчә үзегезне күреп белмәсәләр дә, сезне, Университетның беренче оештырылуыннан ук анда укыган студентны, ә илле ел үткәннән соң аның ачылу көннәрен шул кадәр мавыктыргыч итеп һәм чын күңелдән тасвирлап күрсәткән язучыны, бик нык хөрмәт итәләр.

Безнең бу мәҗлеснең иң кадерле урнында кем утырырга тиеш? Әлбәттә, Россия өчен илле ел буена фикер һәм сүз байлыгы белән гадел хезмәт күрсәткән кеше — сез утырырга тиешсез.

Сезне, беренче чыгарылыш студентны, үзебезнең студентлар мәҗлесенә чакырабыз. Килегез һәм үзегезнең элекке табындашларыгызга бер күренегез, сездән соң укыган студентларга, сезне язучы итеп тирән хөрмәт итүчеләргә, сезнең белән горурланучы Казан студентларына, үзегез белән якыннан танышырга ирек бирегез.

Имзалар:

*Александр Княжевич, Еварест Грубер, Владимир Панаев, Дмитрий Перевощиков, В. Перцэв һ. б.*

С.-Петербург, 1 ноябрь 1857 ел".

... 1857 елның 5 ноябрендә Петербург Шахмат клубында Казан университетының элекке 77 студенты һәм профессорлар җыйнала. Тик Казанның беренче студенты карт Аксаков кына иптәшләре арасында булмый. Аксаков урнына мәҗлескә Москвадан аның улы И. С. Аксаков килә һәм этисенең җавап хатын тапшыра.

„Казан университетының элекке студентлары — кадерле дусларым! Сез һәм сезнең сөекле исемнәрегез миңа Казан гимназиясен, Университет ачылуны, укыган вакытларны, бергәләп үткәргән яшьлек елларын хәтерләтте; сезнең барыгызга да, шулай ук миннән соң укыганнарга да, чын күңелдән рәхмәт белдерәм; мин аларны да кадерле дусларым итеп саныйм, чөнки без барыбыз да бер үк шәһәрдә, бер үк Университетта гомуми белем алган кешеләр. Сез үзегезнең хатыгызда мине үзебезнең уртак бәйрәмгә, Казан университеты ачылу көненә багышлап үткәрелә торган мәҗлескә, чакырасыз; мине, язучы итеп, ягымлы сүзләр белән телгә аласыз, үзегезнең арагызда миңа беренче урынны такдим итәсез; бу хат миңа гаять тирән һәм шатлыклы тәэсир ясады, һәм ул минем йөрәгемдә мәңгегә сакланыр. Мине яхшылык белән искә төшерүегез өчен сез дусларыма һәм иптәшләремә рәхмәтләр укыйм... Сезнең дусларча чакыруыгызны үтәү, Петербургга очып барып, сезнең арагызда, Казан студентлары арасында, мәҗлестә утыру минем өчен нинди зур куаныч булган булыр иде бит! Ләкин күңелсез картлык зәхмәте аркасында күптән инде бары җәй көннәре генә, анда да бик кыска вакытка гына чыгып йөри алам. Шундый зур хозурлыктан мәхрүм булу хәзерге минутта миңа бик авыр булса да, сезнең елы хатыгыз, сезнең дус күрүегез — мине юата, һәм мин хафаланмыйм. Бишенче ноябрь көнне мин үземне сезнең арада утырам дип хис итәрмен, бокал күтәреп, сезнең белән бергә: „Яшәсен Казан Университеты, озак еллар чәчәк атып, туган илебезнең файдасы һәм даны өчен рус яшьләренә озак еллар белем һәм яктылык биреп торсын!“ дип кычкырырмын!“

*В. Берлянд.*